**СОВЕТ НАРМОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422630 ,РТ, Лаишевский район,
село нармонка, ул.Молодежная, д.12а
Тел: 8 (84378) 4-62-24
Факс: 8 (84378) 4-62-24

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН НАРМОНКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422610 Лаеш районы,Нармонка авылы
Яшьлэр ур., 12 а анчейорт
Тел: 8 (84378) 4-62-24
Факс: 8 (84378) 4-62-24

---

**2024 елның 8 ноябре** **232 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең Карадүле торак пунктында гражданнар җыены карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлегендәге Карадүле торак пункты гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең Карадүле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2024 елда үзара салым салу акчаларын 1250 сум күләмендә түбәндәге эшләрне эшләргә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту буенча эшләр өчен түләүгә юллау.

3. Әлеге карарны Нармонка авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: _________________ **И.Ф. Мөбәрәкшин**
(имза) (имза расшифровкасы)

**Башлык-Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге Советы рәисе вазыйфаларын башкаручы:_________________** **И.Ф. Мөбәрәкшин**
(имза)(имза расшифровкасы)